КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 1 ноябрь г.Казань № 998

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (კарарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең бу карар нигезендә билгеләнә торган эш хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи йөкләмәләре күләмен саклау һәм алар шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шартын үтәп, бу карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкән вакытта гамәлдә булган

хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган эш хакыннан кимрәк була алмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар җитәкчеләренә, тиешле һөнәр берлекләре органы белән килештереп:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренә бу карар белән билгеләнгән хезмәт өчен түләү системасын керткәнгә кадәр ике айдан да соңга калмыйча хезмәтнең шактый шартлары үзгәрү турында хәбәр итәргә.

4. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарының гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагындагы аерым оешмаларга кагылмый.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин